**МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.09.2019 г. Казань № 882 од

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2007 елның 4 июнендәге 343 номерлы боерыгы белән расланган Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗат коллективлары проектларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗат коллективлары проектларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын гамәлгә кую турында» 2007 елның 14 маендагы 181 номерлы карары нигезендә

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗат коллективлары проектларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары турында» 2007 елның 4 июнендәге 343 номерлы боерыгы белән расланган Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗат коллективлары проектларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турында нигезләмәгә (2009 елның 31 мартындагы 173 номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), аны кушымта итеп бирелгән яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.
2. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары Ю.И. Әдһәмовка йөкләргә.

**Министр** **И.Х. Әюпова**

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
2007 елның 4 июнендәге 343
номерлы боерыгы белән
(2009 елның 31 мартындагы
173 номерлы, 2019 елның 11
сентябрендәге 882 од
номерлы боерыклары
редакциясендә) расланган

**Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗат коллективлары проектларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турында**
**нигезләмә**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗат коллективлары проектларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турындагы әлеге нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) «Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законының 28.2 статьясын гамәлгә ашыру максатыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗат коллективлары проектларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын гамәлгә кую турында» 2007 елның 14 маендагы 181 номерлы карары нигезендә эшләнде.

1.2. Әлеге Нигезләмә муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗат коллективлары проектларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын (алга таба – грантлар) ел саен бирү тәртибен билгели.

1.3. Конкурста гамәлгә куючылары Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары булган Татарстан Республикасының муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләре (алга таба – муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре) катнаша.

1.4. Грантлар кире кайтарылмый торган максатчан субсидияләр рәвешендә бирелә.

1.5. Әлеге Нигезләмә нигезендә грантлар бирү Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларыннан тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы» ведомствосы буенча күрсәтелгән максатларга каралган

бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә тигез өлешле финанслау шартларында гамәлгә ашырыла. Грантлар алучыларга муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре керә, шул ук вакытта төгәл бер номинация буенча грант түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетыннан бүлеп бирелә торган акчалар күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән бүлеп бирелә торган акчалар күләменә тигез була.

1.6. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

грантлар - субсидияләр рәвешендә бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары;

грант бирүче - муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренә грантлар бирүне Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы– Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба – Министрлык) аша гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты (Татарстан Республикасы Хөкүмәте);

конкурс - грантлар бирү өчен муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗат коллективлары проектларын конкурс нигезендә сайлап алуга бәйле чара;

гариза бирүче - конкурста катнашу өчен гариза документларын тапшырган муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениесе;

грант алучы - конкурсның җиңүчесе дип танылган муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениесе;

хисап чоры - грантлар бирелгән елдан соң килә торган финанс елы.

1.7. Әлеге нигезләмә кысаларында вәкаләтле орган буларак Министрлык:

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтына конкурс, конкурста катнашучыларга карата таләпләр һәм аның нәтиҗәләре турында мәгълүматлар урнаштыруны тәэмин итә;

конкурста катнашу өчен гаризаларны (алга таба - гаризалар) һәм аларга кушып бирелгән документларны кабул итүне һәм теркәүне оештыра;

муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗат коллективлары проектларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алучыларны билгеләү Советы (алга таба - грантлар буенча Совет) эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениесенә грант бирелгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башкарма комитеты белән грантлар бирү турында килешүләр төзи;

бирелгән грантларның максатчан тотылуын тикшереп торуны гамәлгә ашыра.

## 2. ГРАНТЛАР БИРҮ ТӘРТИБЕ

2.1. Грантлар, һәр номинация буенча хупланган проектларның билгеләнгән санына карап, түбәндәге номинацияләр буенча бирелә:

| Номинацияләр исемлеге | Хупланган проектлар саны | Бер грантны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган акчалар күләме |
|---|---|---|
| мәдәни-ял итү эшчәнлеге | 23 | 200 000 |
| китапханә эше | 16 | 150 000 |
| музей-күргәзмә эшчәнлеге һәм халык сәнгать кәсепләре | 6 | 200 000 |
| театр һәм музыка сәнгате | 3 | 200 000 |
| кинематография | 3 | 200 000 |
| сәнгати-эстетик белем бирү | 14 | 150 000 |

2 300 (ике мең өч йөз) сум күләмендә бүленмәгән лимит Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

2.2. Конкурсны үткәрү сроклары ел саен Министрлык боерыгы белән раслана һәм Министрлыкның Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына Конкурсны үткәрү турында карар кабул ителгән көннән соң өч көн эчендә урнаштырыла.

2.3. Грант алуга конкурста катнашу өчен муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениесе Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада карлаган грант алуга гариза;

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада каралган төгәл бер проектны гамәлгә ашыру өчен чыгымнар сметасы;

әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымтада каралган иҗади проектны тормышка ашыру буенча чаралар планы («юл картасы»);

иҗади проектны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетыннан тигез өлешле финанслау шартларында финанслашу турында гарантия хаты;

карала торган проблема буенча (булган очракта) үткәрелгән социологик тикшеренү нәтиҗәләре.

2.4. Гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар турыдан-туры Министрлыкка кәгазьдә һәм электрон чыганакларда (флеш-туплагычларда) әлеге Нигезләмәнең 2.2 пункты нигезендә Министрлык тарафыннан билгеләнгән срокларда тапшырыла. Гаризалар бирү сроклары чыкканнан соң тапшырылган гаризалар кабул ителми һәм мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарыла.

2.5. Конкурс сайлап алуында катнашудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

әлеге Нигезләмәнең 2.3. пунктында күрсәтелгән документларның тулы пакеты булмау;

документларда дөрес булмаган мәгълүматлар булу;

гариза бирүче муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениесе түгел;

тәкъдим ителгән проектка агымдагы финанс елында Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс чаралары алынган;

мөрәҗәгать итүче чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, салым салуның ташламалы салым режимын бирүче һәм (яки) финанс операцияләрен (офшор зоналары) үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләттә (территориядә) теркәлгән чит ил юридик затларына туры килә торган өлеш барлыгы 50 проценттан артып китми торган Россия юридик заты булып тора;

гариза бирүченең хокукый акт нигезендә грант бирү планлаштырылган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетына шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, әгәр мондый таләп хокукый актта каралган булса, һәм хокукый акт нигезендә грант бирү планлаштырыла торган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетына вакыты чыккан башка бурыч булу;

гариза бирүченең әлеге Нигезләмәнең 2.2. пункты нигезендә документларны кабул итүнең беренче көне итеп билгеләнгән датага Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булу;

гариза бирүчегә карата бетерү яки банкротлыкка чыгару процессы алып барыла.

2.6. Конкурста катнашу өчен бирелгән гаризалар рецензияләнми, кире кайтарылмый һәм Министрлыкта билгеләнгән тәртиптә саклана.

2.7. Төгәл бер номинация буенча гариза документлары тапшырылмаган очракта, шулай ук төгәл бер номинация буенча грант алуга документлар бары тик бер муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениесеннән генә тапшырылган булса, әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктында билгеләнгән номинацияләр саны киметелә. Шул ук вакытта хупланган проектлар саны һәм төгәл бер номинация буенча каралган чаралар башка номинацияләр буенча проектларга ярдәм итү өчен грантлар буенча Совет карары белән яңадан җибәрелә.

Грантлар буенча Совет составы Министрлык, Татарстан Республикасының дәүләт мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләре, иҗтимагый оешмалар вәкилләреннән төзелә һәм Министрлык боерыгы белән раслана.

2.8. Әлеге Нигезләмнең 2.3. пунктта тәкъдим ителгән документлар исемлеге нигезендә конкурсга катнашуга кертелгән һәр проект грантлар буенча Совет составына керүче ике эксперт тарафыннан карала.

2.9. Проектны караган экспертларның бәяләүләрендә 35 һәм аннан да күбрәк баллга аерма булса, проект грантлар буенча Совет тарафыннан билгеләнә торган өченче эксперт тарафыннан карала.

2.10. Проектлар экспертлар тарафыннан түбәндәге критерийлар төркемнәре буенча бәяләнә:

| № т/с | Гаризаларны бәяләү критериелары | Бәяләү (баллар) |
|---|---|---|
| 1. | Проектның әһәмияте һәм актуальлеге критериелары | |
| 1.1 | Иҗади проектның максатлары һәм бурычларының актуальлеге һәм конкурс юнәлешләренә туры килүе | 0-10 |
| 1.2 | Проект чараларының логикага туры килүе, үзара бәйләнешле һәм эзлекле булуы | 0-10 |
| 1.3 | Проектның уникальлеге, новаторлыгы, тәкъдим ителә торган карарларның, технологияләрнең һәм алымнарның инновациялелеге | 0-10 |
| 2. | Икътисадый нәтиҗәлелек критериелары | |
| 2.1 | Проектны гамәлгә ашыруга планлаштырыла торган чыгымнарның һәм аннан көтелә торган нәтиҗәләрнең чагыштырмасы | 0-10 |
| 2.2 | Проектны гамәлгә ашыру чыгымнарының нигезлелеге | 0-10 |
| 2.3 | Проектның тотрыклылыгы-грант финанславы тәмамланганнан соң проектны дәвам итү һәм үстерү мөмкинлеге | 0-10 |
| 3. | Социаль нәтиҗәлелек критериелары | |
| 3.1 | Грант алырга теләүчеләр тарафыннан коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларның иҗади проектларны гамәлгә ашыру өчен җәлеп ителүе | Әйе - 1,<br>Юк - 0 |
| 3.2 | Проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелегенең план буенча күрсәткечләре, аларның проект бурычларына туры килүе | 0-10 |
| 3.3 | Планлаштырылган чараларның проектны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләренә туры килүе | 0-5 |
| 3.4 | Проект чараларының максатчан төркем торышын | 0-5 |

| | | |
|---|---|---|
| | яхшыртуга (социумдагы уңай үзгәрешләр, төгәл бер социаль проблемаларны хәл итү, максатчан төркемнең тормыш сыйфатын күтәрү һ.б.) йогынтысы дәрәҗәсе | |
| 4. | Һөнәри компетенция критериелары | |
| 4.1 | Грант алырга теләүчеләрнең проект буенча күз алдында тотылган эшчәнлекне гамәлгә ашыру буенча тәҗрибәсе булу | Әйе - 1,<br>Юк - 0 |
| 5. | Өстәмә критерийлар | |
| 5.1 | Проектның масштабы, җәлеп ителгән иҗади көчләрнең сәнгати статусы | 0-5 |
| 5.2 | Проект берничә муниципаль район һәм/яки шәһәр округы территориясендә гамәлгә ашырыла | Әйе - 1,<br>Юк - 0 |
| 5.3 | Карала торган проблематика буенча үткәрелгән социологик тикшеренүләр булу | Әйе - 1,<br>Юк - 0 |
| **Барлыгы:** | | **0-89** |

2.11. Экспертлар аларга Министрлык гаризаларны тапшырган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көнлек срокта гаризаларны һәм аларга кушып бирелгән документларны карый һәм эксперт бәяләмәләрен Министрлыкка тапшыра. Гаризаларга эксперт бәяләвен үткәрү барышында экспертка билгеле булган мәгълүмат конфиденциаль булып тора һәм фаш ителергә тиеш түгел.

2.12. Министрлык әлеге Нигезләмәнең 2.1. пунктында билгеләнгән һәр номинация буенча, эксперт бәяләмәләренә нигезләнеп, гаризалар рейтингын төзи һәм аларны грантлар буенча Совет раславына тапшыра.

2.13. Гаризалар бирү вакыты тәмамланганнан соң 30 көн эчендә грантлар буенча Совет һәр номинация буенча грант алучылар исемлеген билгели. Грантлар буенча Совет карары Министрлык боерыгы белән раслана.

2.14. Министрлыкның грантлар буенча Совет карарын раслау турында боерыгы нигезендә Министрлык һәм муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениесенә грант бирелгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башкарма комитеты арасында грант алучылар турында Министрлык боерыгы чыгарылган көннән алып 30 көн эчендә килешү төзелә.

2.15. Килешүдә грант күләме, аның максатчан билгеләнеше, аны күчерү тәртибе һәм сроклары, аны куллану турында хисап тапшыру тәртибе, сроклары һәм формасы, әлеге Нигезләмәдә күрсәтелгән очраклардагрантны кире кайтару тәртибе, грант алучының Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан грант бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлүне тикшерүгә ризалык бирү, килешү шартларын бозган өчен җаваплылык карала, шулай ук Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм Татарстан Республикасының тиешле

муниципаль берәмлеге бюджетыннан тигез өлешле финанслангандa грант бирү турында мәҗбүри шарт күрсәтелә. Килешү формасы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан раслана.

2.16. Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениесенә грант бирелгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башкарма комитеты тигез өлешле финанслаудан баш тарткан очракта, грантлар буенча Совет грантны башка грант алучыга бирү турында карар кабул итә. Карар Министрлык боерыгы белән раслана.

2.17. Грантлар акчалардан файдалану турында хисап тапшырылган көннән соң 60 көн эчендә түбәндәге очракларда Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш:

грант алучы дөрес булмаган белешмәләр тапшырган;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге әлеге Нигезләмәнең 1.5. пунктында күрсәтелгән грантны финанслашу шартларын үтәмәгән;

грантлар максатчан файдаланмаган.

2.18. Грантның максатчан файдаланылмавы факты ачыклану турында муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениесенә Министрлык муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениесе тарафыннан грантның максатчан файдаланылмавы факты ачыкланган көннән алып календарь көннәрендә исәпләнә торган 10 көнлек срокта хәбәр итә.

2.19. Грант алучы грантны кире кайтару өчен билгеләнгән срокны бозганда, Министрлык грантның максатчан файдаланылмавы факты ачыклаган көннән соң 30 көн эчендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениесе тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына грантны кире кайтару буенча чаралар күрә.

2.20. Финанс хисап елында муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениесе тарафыннан файдаланылмыйча калган грант акчалары Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

2.21. Грантлар бирү турында боерык чыгарылган көннән алып биш көн эчендә Министрлыкның рәсми сайтына грант алучылар турында мәгълүмат урнаштырыла.

## 3. ГРАНТ АЛУЧЫЛАРГА АКЧА ТҮЛӘҮ ТӘРТИБЕ

3.1. Грант алучыларга акча күчерү, Министрлык һәм муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениесенә грант бирелгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башкарма комитеты арасындагы килешүләргә нигезләнеп, Министрлык тарафыннан Федераль казначылык идарәсенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органында ачылган лицевой счетларга субсидияләр рәвешендә гамәлгә ашырыла.

# 4. ГРАНТ АЛУЧЫЛАР ТАРАФЫННАН ХИСАПЛАР БИРҮ ТӘРТИБЕ ҺӘМ СРОКЛАРЫ

4.1. Грант алучылар Министрлыкка грантлар түләүгә бүлеп бирелгән акчалардан максатчан файдалану һәм иҗади эшчәнлек нәтиҗәләре турында хисапларны хисап чорыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр тапшыралар.

4.2. Иҗади эшчәнлек нәтиҗәләре турында хисапта түбәндәге позицияләрне күрсәтү тәкъдим ителә:

куелган максатларга һәм бурычларга ирешү;

гариза формасында күрсәтелгән сыйфат һәм сан нәтиҗәләренә ирешү;

иҗади проектны тормышка ашырудан социаль нәтиҗә;

иҗади проектны киләчәктә гамәлгә ашыру һәм аны тиражлау мөмкинлеге;

учреждениенең иҗади проектны тормышка ашыру буенча иҗади эшчәнлеге турында җәмәгатьчелек фикеренә (массакүләм мәгълүмат чаралары хәбәрләренә) күзәтү;

иҗади проектны гамәлгә ашыру буенча фотоматериаллар.

4.3. Грантлар түләүгә бүлеп бирелгән акчалардан максатчан файдалану турындагы хисап әлеге Нигезләмәнең 2.15 пунктында каралган килешүгә кушымта итеп бирелгән форма буенча өч нөсхәдә язма рәвештә тапшырыла.

4.4. Хисапка беренчел финанс документлары күчермәләре теркәлә.

4.5. Грант алучылар тарафыннан аларны бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлүен, грантларны максатчан файдаланылуын тикшереп торуны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри тикшерүләр үткәрү юлы белән Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы башкара.

Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗат коллективлары проектларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗат коллективлары проектларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алуга
**гариза формасы**

| | |
|---|---|
| Номинациянең исеме | |
| Проектның исеме | |
| Проектның кыскача эчтәлеге | *Проектның төп идеясен чагылдырган проект тексты презентациясе (1000нән артык булмаган символ)* |
| Проектның социаль әһәмиятлелеген нигезләү | *Монда проектны булдыруга этәргән вәзгыятьне тасвирлау тәкъдим ителә. Карала торган проблематика буенча социологик тикшеренүләр булу. Финанс чаралары булмау проблема булып тормый. Проблема дигәндә мәдәният, сәнгать өлкәсендә урнаша торган һәм аны хәл итү өчен проект тәкъдим ителә торган вәзгыять аңлашыла. Проблемалар тасвирламасыннан соң проектның аңа логик яктан бәйле максатлары һәм бурычлары күрсәтелергә тиеш (1000 символдан артык түгел)* |
| Проектның максаты һәм бурычлары | *Максатлар гомуми терминнарда формалаша, шул ук вакытта бурычлар эшчәнлекнең төгәл бер нәтиҗәләрен билгели. Нәтиҗәдә сез ирешергә теләгәннәрне билгели торган бурычларны сез эшләргә теләгәннәр белән бутарга кирәк түгел* |
| Көтелгән нәтиҗәләр | |
| Микъдарлы нәтиҗәләр | *Төгәл, санлы күрсәткечләр белән исәпләнә торган нәтиҗәләр һәм проектны гамәлгә ашыру чорында ирешү планлаштырылган күрсәткечләрнең план буенча күрсәткечләре* |

| | |
|---|---|
| | *билгеләнә.* |
| Сыйфат нәтиҗәләре | *Проектны гамәлгә ашыру чорында ирешү планлаштырыла торган, санлы күрсәткечләрдә исәпләнми торган нәтиҗәләр күрсәтелә (социумдагы уңай үзгәрешләр, төгәл социаль проблемаларны хәл итү, максатчан төркемнең тормыш сыйфатын күтәрү һ. б., 1000 символдан да күп түгел)* |
| Сорала торган грант суммасы, шул исәптән түбәндәгеләр хисабына:<br>– республика бюджеты;<br>– җирле бюджет;<br>– финанслауның башка чыганаклары (аларны күрсәтергә) | – __________ сум,<br>– __________ сум,<br>– __________ сум |
| Чыгымнар сметасы | *учреждение җитәкчесе, хисапчысы имзасы һәм учреждениенең мөһере белән расланган аерым биттә (форма кушымта итеп бирелә)* |
| Проектны гамәлгә ашыру сроклары | |
| Проектны гамәлгә ашыра башлау датасы | *(ай, ел)* |
| Проектны гамәлгә ашыру тәгәлләнү датасы | *(ай, ел)* |
| Партнерларның ниятләрен раслый торган документлар | *Проектны гамәлгә ашыруга мәгълүмати, консультация, оештыру, матди һәм (яки) башка ярдәм күрсәтергә әзер булган 10 партнерга кадәр (оешмалар һәм (яки) физик затлар) күрсәтелә.*<br>*Гаризага гариза бирүче теләге буенча беркетелә (проектны гамәлдә ашыруда төп партнерларның (югарыда санап кителгәннәрдән) роле һәм төгәл катнашу формалары турында мәгълүматны үз эченә алган 5 документтан да күп түгел).* |
| Проектларны бергәләп гамәлгә ашыру өчен коммерциягә | *Оешмалар исемлеге күрсәтелә* |

| | |
|---|---|
| карамаган социаль юнәлешле оешмаларны җәлеп итү | |
| Грант алырга теләүчеләрнең проект буенча күз алдында тотылган эшчәнлекне гамәлгә ашыру буенча тәҗрибәсе булу | Әйе/ юк<br>*Эшчәнлек төрләрен кыскача тасвирларга һәм оешманың төп иҗади эшләрен санап чыгарга, охшаш проектларны гамәлгә ашырганда ирешелгән нәтиҗәләрне күрсәтергә* |
| Соңгы өч елда оешмага грант ярдәме күрсәтелдеме | *Конкурсларның, иҗади проектларның исемен, грант күләмен, алган елны күрсәтергә* |
| Проектта катнашучыларның күз алдында тоткан аудиториясе һәм географиясе, сан ягыннан составы | |
| Проектны гамәлгә ашыру планлаштырыла торган территория (торак пунктлар, муниципаль берәмлекләр, аларны күрсәтергә) | *Торак пунктлар, муниципаль берәмлекләр исемлеге күрсәтелә* |
| Эшчәнлек ысуллары | *Монда түбәндәгеләрне күрсәтү киңәш ителә:*<br>*– эш ничек башкарылачак һәм ни өчен нәкъ менә шундый эшчәнлек ысулы сайлап алынган;*<br>*– проектта катнашучы башкаручылар нәрсә белән шөгыльләнәчәк;*<br>*– чара ничек узачак (яки эшчәнлек продуктлары ничек сатылачак);*<br>*– өстәмә ресурслар кайда һәм ничек җәлеп ителәчәк* |
| Учреждениенең тулы исеме (теркәлү турында таныклыкта күрсәтелгәнчә) | |
| Проект авторлары (Ф.И.А.и., вазыйфасы) | |
| Учреждениенең почта адресы | |
| Элемтә өчен телефон | |
| Электрон почта адресы | |

*Гаризага теркәп бирелә торган документлар:*

1. Теркәлү турында таныклык күчермәсе.
2. Оешманың уставы күчермәсе.
3. Оешманы дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе, шулай ук гамәлгә кую документларына кертелә торган үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алу турында ЕГРЮЛга язу кертү турында таныклык күчермәсе.
4. Салым органында исәпкә куелу турында таныклык күчермәсе.
5. Учреждение җитәкчесе вәкаләтләрен раслаучы документ.

Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗат коллективлары проектларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

РАСЛЫЙМ

___________________________

(оешма җитәкчесе: вазыйфасы, Ф.И.А.и.)

«____» __________, 20__ ел

Мөһер урыны

Проектны тормышка ашыруга чыгымнар сметасы

______________________________________________________________

сум

| **Статьяның исеме** | **ТР бюджеты акчалары** | **Җирле бюджет акчалары** | **Финанслауның башка чыганаклары акчалары** | **Барлыгы** |
|---|---|---|---|---|
| **Хезмәт өчен түләү*** | | | | |
| Штаттагы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү | – | – | | |
| Штаттагы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүне хисаплау | – | – | | |
| Күрсәтелә торган хезмәтләр өчен штаттан тыш хезмәткәрләрнең (экспертлар, консультантлар һ. б.) хезмәте өчен түләү | – | | | |
| Штаттан тыш хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүне хисаплау | – | | | |

* Хезмәт өчен түләү проектта каралмаган булырга мөмкин.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Хезмәт өчен түләү буенча барлыгы** | – | | | |
| **Турыдан-туры чыгымнар** | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| **Турыдан-туры чыгымнар буенча барлыгы** | | | | |
| **Проект буенча башка чыгымнар** | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| **Барлык башка чыгымнар** | | | | |
| **Проект буенча барлык чыгымнар** | | | | |

Баш хисапчы (хисапчы) _______________________ И.А.и. Фамилия
(имза)

ТР бюджеты акчалары исәбеннән **түбәндәге чыгымнар** финансланмый:

– учреждениенең көндәлек чыгымнары: хезмәткәрләрнең хезмәт хакы (шул исәптән - җәлеп ителгән белгечләрнең хезмәте өчен түләү), бинаны арендалау, шулай ук гамәлгә ашырылган яки агымдагы проект буенча чыгымнар;

– коммерциягә караган проектлар;

– проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле булмаган җиһазларны сатып алу;

– офис җиһазлары сатып алу;

– бинага ремонт эшләре үткәрү.

Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗат коллективлары проектларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турында нигезләмәгә 3 нче кушымта

**Иҗади проектны тормышка ашыру буенча чаралар планы («юл картасы»)**

| № т/б | Иҗади проектның бурычлары исеме | Проектны тормышка ашыру буенча чаралар исемлеге | Тормышка ашыру | Көтел |
|---|---|---|---|---|

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | сроклары | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |